# “*Әбиемнең затлы сандыгы” – татар халкының орнаментлары белән танышу*

**Бакчабызда сары көзләр житүгә уыңыш бәйрәме «Сөмбеләне кем белә?, «Каз өмәсе» бәйрәмнәре үткәрелә.Эле бу елның вакыты килеп житмәсә дә, алдагы елның «Каз өмәсен» ьдим итәсебез килде.**

**Әниләр белән берлектә шадра ак сөлгедән казлар тектек, каз канатлары, сыдыру өчен каурыйларын өйдән алып килдек. Барысын да балаларга борынгы өмәләр ничек булган шулай өйрәтәбез. Шаярулар, малайларның җырлап килүләре, бергә парлы җырлы-биюле нар берсе дә калмый. Билгеле каз өмәсе каз коймагыннан башка була да алмый, тәмле каз коймагы белән балалар  сыйланалар. Ул коймакның тәме дә икенче үзгә була шул.**





